ГЛАВА ОЛУЯЗСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ш.Маннура, д.72а, с. Олуяз,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422146

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫЯЗ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ш.Маннур ур., 72а нчы йорт, Олыяз авылы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422146

тел.(факс): (85563) 2-25-82; e-mail: Olu.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

Карар — Постановление
05.11.2019 ел. — № 11

Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Тулбай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» гы 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Олыяз авыл җирлеге муниципаль берәмлеге” Уставының 23 статьясы нигезендә карар бирәм :

1. Татарстан Республикасы, Мамадыш муниципаль районы, Тулбай авылы , Пионер урамы , 9 нче йорт адресы буенча урнашкан Тулбай авыл клубы бинасында 2019 елның 20 ноябрендэ сәгать 11.00 дэ Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Тулбай авылы торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

"Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлегенең Тулбай авылы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны түбәндәге җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

- Тулбай авылы торак пунктындагы Совет урамында Боек Ватан сугышында һәләк булучылар очен һәйкәл кую.

-Тулбай авылы торак пунктына янгын ранецлары сатып алу;
- Тулбай авылы торак пунктындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту;

« ӘЙЕ» «ЮК».

3. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Олыяз авыл җирлеге башкарма комитетына Тулбай авылында гражданнар җыенын оештыруны һәм уздыруны йөкләргә .

4. Әлеге карарны кабул иткәннән соң 3 көн эчендә муниципаль берәмлек Советының мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) сайтында урнаштырырга.

5. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Мамадыш муниципаль районы
Олыяз авыл җирлеге башлыгы: И.Я.Хаев